СӨЙ ТУГАН ТЕЛЕҢНЕ, СӨЙ ХАЛКЫҢНЫ, СӨЙ ХАЛКЫҢНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

24 гыйнвар, 1997ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.

№ 8 (8020)

Бәясе билгеләнгәнчә

**Иртәгә агропромышленность комплексы алдынгыларының традицион район слеты уздырыла.**

**Слетта катнашучыларга кайнар сәлам!**

## ИГӘ БЕЛГӘН - ИКМӘКЛЕ

**Бөртекле культуралардан иң югары уңыш алган хуҗалыклар**

«Норлатнефть» НГДУсының «Дуслык» ярдәмче хуҗалыгында бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 42,5әр центнер уңыш җыеп алдылар.

***

Мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмәдә һәр гектардан 41,3 центнер булды.

***

Мичурин исемендәге КХАда ул күрсәткеч 36,2 центнер тәшкил итте.

**Тупас һәм сусыл азык әзерләү буенча алдынгы хуҗалыклар**

«Дуслык» ярдәмче хуҗалыгында бер шартлы терлеккә 55,3 центнер азык берәмлегә әзерләнде.

Муса Җәлил исемендәге КХАда ул күрсәткеч 35,1 центнер булды.

«Кондырча» хуҗалыгында моннан аз гына, бары тик 0,1 центнерга гына калыштылар.

## ҺАВАЛАНЫР ЧАК ТҮГЕЛ

***Иртәгә район мәдәният йорты агропромышленность тармагының хезмәт алдынгылары: урак батырлары һәм ферма уңганнары, продукция муллыгы өчен көрәштә фидакарь хезмәтләре белән катнашучылар карамагына биреләчәк - районда алдынгыларның традицион слеты уздырыла.***

***Традицион бу чараның быел төп максаты нидән гыйбарәт соң? - район авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе начальнигы Ә.Н.РӘХМӘТУЛЛИН белән әңгәмәбез шул хакта.***

**-Әнәс Нәбиуллович, сер түгел, слетка чакырылучылар аннан бүләксез кайтмаячакларын белеп киләләр бит инде...**

- Ел буена киеренке хезмәт куйган, районда башкаларга үрнәк алырлык күрсәткечләргә ирешкән эш кешесен бүләкләү һич тә артык түгел дип саныйм. Үз вазифасын ел тәүлеге намус белән башкарган терлекче яки кыр хезмәтчәне теге яки бу хуҗалыкта җитәкчеләр яки белгечләр эшне дөрес итеп оештырмаганга күрә генә нәүмиз калырга тиеш түгел бит. Шулай да бүләкнең иң затлылары күрсәткечләре башкаларга өлге булырдайларга биреләчәк. Хезмәткә түләүдәге кебек үк бу мәсьәләдә дә тигезләүчелек булырга мөмкин түгел.

**- Эшенә күрә - ашыдигән нәрсә анысы элек - электән килә бит инде.**


- Шулаен шулай да бит, әмма менә мондый тантаналы чаралар килеп җитсә, кемнеңдер ел дәвамында эленке - салынкы гына йөргәнлеге дә онытыла шул кайчак. Ә менә хезмәт кешесен яхшырак, нәтиҗәлерәк эшләүгә кызыксындырыйк дисәк, аның хезмәтенә дә ахыр нәтиҗәләрдән чыгып түләү принцибы сакланырга тиеш. Әнә былтыр бөртеклеләрдән 24,7шәр центнер уңыш белән калдык. Безнең район җирләре өчен һич тә төс түгел бит бу. Җиде хуҗалыкта гектардан уңышны 30 центнердан арттыра алдылар бит. Слетта алар мактап телгә алыначаклар, билгеле. Шул ук вакытта алты хуҗалыкта уңыш 20 центнерга да тулмады. Терлек азыгы хәзерләү мәсьәләсендә дә хәл шундый ук. Район буенча бер шартлы терлеккә 27,3 центнер азык берәмлеге туплап куелса, ул күрсәткечне 20 центнерга да тутыра алмаучылар булды. Һәм, үч иткәндәй, тегеләре дә, болары да бер үк хуҗалыклар диярлек. Шуңа да бүген алар малларны кышлатуны бик авырлык белән алып баралар. Һәм андыйлар алдынгылар слетыннан киләчәктә ничек тә яхшырак эшләүне белән китәрләр дип ышанасы килә.

**- Ничек тә дигәннән, элегрәк авыл хуҗалыгында продукцияне нинди юл белән булса да күбрәк җитештерү бурычы куела торган иде...**

- Хәзер ул турыда сүз дә булырга мөмкин түгел. Терлекчелекне генә алыйк менә.

**(Ахыры 2 нче биттә.)**

## КИЛДЕ ТАТЛЫ ҖИҢҮ МИЗГЕЛЛӘРЕ...




Йокыны - ялны онытып куйган фидакарь хезмәтнең җиңү мизгелләре ничек кадерле, нинди татлы булуын белсәгез икән. Ул бик тырыш, бик омтылышлы кешеләргә генә насыйп була. «Алга» крестьян хуҗалыклары ассоциациясе комбайнчысы Рәшит Кәлимуллович Насыйбуллин аны тормышының иң мөһим вакыйгасы итеп саный. Узган уракта ул «Дон - 1500» комбайнында ярдәмчесе Айрат Насыйбуллин белән 30736 центнер ашлык суктырып, район игенчеләренең иң гаярьләре, иң уңганнарын да шаккатырды.

Рәсемдә: «Алга» КХАсы рәисе урынбасары Т.А.Садретдинов кыр батырын зур җиңүләре белән котлый. Янәшәдә - шофер Валерий Емельянов. Ул урак барышында Рәшит суктырган ашлыкны комбайннан ындыр табагына ташып торды.

**1996 елда шикәр чөгендерен ташу буенча алдынгы шоферлар**

Беренче урынга Кикекле кырларыннан чөгендер ташучы УТТ шоферы Минсәлих Минтаһирович Гобәйдуллин чыкты. Аның күрсәткече бер тонна йөк күтәрешенә 5025 тонна - километрны тәшкил итте.

Икенче, өченче урыннарны Әлмәт КХАсыннан Хәлим Әхтәмович Хәсәнов (4525 тонна - километр) һәм «Москва» КХАсы шоферы Геннадий Филлипович Светкин (3157 тонна - километр) бүлештеләр.

## Кемнең сыеры сөтлерәк?

**1996 ел йомгаклары буенча сыерларның продуктлылыгы буенча алдынгы хуҗалыклар**

«Кондырча» ассоциациясендә бер сыердан 4781 килограмм сөт савып алынды.

«Рассвет» КХАсында бу күрсәткеч 3504 булды.

«Чирмешән» хуҗалыгында алдагыдан бары тик 260 килограммга калыштылар.

**Районның алдынгы сыер савучылары**

«Кондырча» КХАсыннан Саимә Вәлиәхмәтовна Ибәтуллина беренче урынны яулады: ул бер сыердан 5129 килограмм сөт сауды.

Мичурин исемендәге ассоциациядән Валентина Васильевна Тимофееваның күрсәткече 4535 килограмм булды.

«Рассвет»тан Хәнифә Вәлияровна Сатдарова өченче урынга чыкты һәм һәр сыердан 3974 килограмм сөт сауды.

**Беренче бозаулаган таналарны савучы алдынгылар**

«Игенче» ассоциациясе савучысы Рәисә Ибраһимовна Галләмова бер сыердан 4150 килограмм сөт савып алды.

Мичурин исемендәге КХАдан Анастасия Федоровна Ивашкинаның күрсәткече алдагысыннан 45 килограммга гына азрак булды.

Кондырчалы Мөкәррәмә Рифкатовна Монасыйпова һәр сыердан 4093 килограмм сөт сауды.

## ИТНЕ БАРЫБЫЗ ДА ЯРАТА

**Ит җитештерү һәм сату буенча алдынгы хуҗалыклар**

«Родина» КХАсында ит җитештерү алдагы елдагы белән чагыштырганда 107 процентка, ә сату 150 процентка үтәлгән.

«Рассвет» КФХАсында ит җитештерү алдагы елдан 11 процентка кимрәк җитештерелгән аның каравы 73 процентка артыграк сатылган.

Чирмешәнлеләр җитештерүне 110, ә сатуны 102 процентка үтәгәннәр.

**Районның алдынгы бозау караучылары**

Кузнецов исемендәге ассоциациядән Лидия Петровна Яллина бозауларының уртача тәүлеклек артымы 746 грамм булды.

Мичурин исемендәге хуҗалыктан Валентина Николаевна Иванова икенче урынга чыкты, ул уртача тәүлеклек артымны 1995 елдагыдан 76 граммга арттырды.

Синдряков исемендәге КХАдан Мария Валентиновна Трифонованың күрсәткече 705 граммга җитте.

**Мөгезле эре терлек симертү буенча алдынгы терлекчеләр**

Якты Күл КХАсыннан Ибраһим Галимҗанович һәм Хәниф Галимҗанович (вафат булды) Гыйззәтуллиннарның аренда подряды беренчелекне яулады, аларның малларының уртача тәүлеклек артымы 1100 граммга җитте.

Мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмәдән Юныс Галиуллович Әхмәтсафинның күрсәткече 778 грамм булды.

«Татарстан» КХАсы терлекчесе Вакыйф Заһидуллович Хәлиуллин өченче урынга чыкты.

**Дуңгыз симертү осталары**

Синдряков исемендәге ассоциациядән Сергей Иванович Маськин иң югары нәтиҗәне бирде - аның дуңгызларының уртача тәүлеклек артымы 410 грамм булды.

«Рассвет» КХАсыннан Гөлсинә Габделнуровна Мәнапова, Галина Николаевна Синцова, Надежда Петровна Бурнаевскаяның аренда коллективы икенче урынга чыкты, аларның күрсәткече 355 грамм булды.

# ЕЛ ТӘҮЛЕГЕ ҖИҢНӘР СЫЗГАНУЛЫ

## ҺАВАЛАНЫР ЧАК ТҮГЕЛ

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)**

Былтыр районда мөгезле эре терлек һәм дуңгыз итенең үзкыйммәте аны реализацияләү бәясеннән гаять югары булды. Ә шулай кыйммәткә төшереп җитештерү кемгә кирәк ул? Киекле, Мичурин исемендәге, «Знамя Октября», «Алга»,«Әлмәт» хуҗалыкларында җитештерелгән дуңгыз ите алтын бәясенә төште бит былтыр. Сөтне дә сатып алу бәясеннән кыйммәткә җитештерәбез. Өстәвенә, кайбер хуҗалыкларда былтыр бер сыердан 1500 - 1600 килограмм гына сөт савып алдылар. Ә бит ул малларга күпме азык ашатылган, аларны караучыларга күпме хезмәт хакы түләнгән...

**- Акчаны санап тотар вакыт җитте димәкче буласыз инде...**

- Кайберәүләр өчен ул вакыт узып бара инде. Әле менә шушы арада Казанда коллегаларым белән өч көнлек уку - семинарда булдым. Анда төп сүз авыл хуҗалыгының кайсы тармагында да җиргә, башка милеккә чын хуҗа булдыру, чыгымнарга каршы механизмны киң куллanылышка кертү турында барды. Хезмәтне оештыруның аренда, кооператив формаларын киң куллану, нәтиҗә бирми торган чыгымнарны киметү генә түгел, ә бетерү юнәлешендә чынлап торып эшләргә кирәк.

**- Болар хакында гомер - гомергә сүз бара бит инде...**

- Сүздә генә калдырмаска иде шул. Менә бер - ике генә мисал. Бозауларны салкында асрау ысулының нәтиҗәлелеген күрсәтү өчен хуҗалык җитәкчеләрен кая гына алып бармадык. Моны вакытында аңлаган хуҗалар кайтуга эшкә тотындылар һәм хәзер сөенеп бетә алмыйлар. Ә менә вакытында селкенмәгәннәр тагын оттырды. Аннары, сыер фермаларында хезмәт чыгымнарын киметүнең малларны бәйсез араннарда асрау ысулының күп өстенлекләрен күрделәр җитәкчеләр. Инде шуны куллана башлаганнары да бар. Әмма һаман искечә эш алымнарына ябышып ятучылар да җитәрлек. Инде менә бу мәсьәләдә тагын бер тапкыр район семинары уздырырга җыенабыз. Иртәгә булачак слетта да былтыргы эш алдынгыларын санап чыгу һәм бүләкләү белән генә чикләнмәячәкбез, ә ничек итеп алга таба тагын да яхшырак эшләү турында эчкерсез сүз булыр дип өметләнәбез. Югыйсә, кайсы гына тармакны алсак та, күкрәк сугып мактанырлык нәтиҗәләребез бар дип әйтә алмыйбыз бит әле. Инде республикадагы кайбер районнар өчен гадәтигә әверелеп бара торган күрсәткечләр әлегә безнең иң алдынгы дип саналган хуҗалыкларыбызда гына. Һәм алга таба алдынгылар күрсәткечен норма итү өчен интенсив технологияләрне сүздә генә түгел, реаль эштә киң кулланылышка кертү, кайсы гына тармакта да мул продукция генә түгел, мул табыш та бирә торган эш белән шөгыльләнү барыбыз өчен дә анык максат булырга, шуңа ирешү өчен кирәкле булган барлык шартлар тайпылышсыз үтәлергә тиеш.

**- Шуңа ирешә алсак, мондый слетларның чираттагыларында алдынгылар арасыннан иң алдынгыларын сайлап алу да кыен булыр әле.**

-Шулай гына була күрсен.

## Горурланырлыгы бар

«Кондырча» крестьян хуҗалыклары ассоциациясе савучыларының узган елгы ярышында беренче урынга Саимә Ибәтуллина чыкты. Моңа берәү дә гаҗәпләнмәде. Ут кебек җитез, булдыклы, уңган Саимә беренче елын гына эшләми иде бит инде. Авырлыкларга күнгән, аларны зарланусыз күтәрә белгән хатын - кыз буларак та хөрмәт яулаган иде. Әнә бит берүзе өч баласын аякка бастырды, йорт - җирен бер дигән итеп алып бара. Андый кеше төп хезмәт урынында сыната димени? Әлбәттә, юк. Әнә бит үзе караган һәр малдан 5129әр килограмм сөт савып алды, ярышташлары арасында әйдәп баручы булды. «Кондырча» крестьян хуҗалыклары ассоциациясендә бүген дә мул савым, әйбәт күрсәткечләр саклана икән, ул иң әүвәл Саимә һәм аның тырыш хезмәттәшләренең фидакарьлеге нәтиҗәсе. Бу көннәрдә тагы бер нәрсә мәгълүм булды: Сәлимә



Ибәтуллина район сыер савучылары арасындагы ярышта иң зур күрсәткечкә ирешкән икән бит! Бу - савучының үзе өчен генә түгел, тулаем хуҗалык өчен дә зур шатлык, олы горурлык.

**Рәсемдә: сыер савучы С.Г.Ибәтуллина.**

**<u>«Дон - 1500» комбайнында бөртекле һәм бөртекле - кузаклы культуралар суктыру буенча алдынгы комбайнчылар</u>**

«Алга» КХАсыннан Рәшит Кәлимуллович Насыйбуллин 30736 центнер ашлык суктырды.

«Большевик» КХАсы комбайнчысы Александр Егорович Донсковның күрсәткече 18009 центнер булды.

«40 лет Победы» КХАсыннан Владимир Анатольевич Никитин анардан 1068 центнерга гына калышты.

***

**<u>СК - 5 комбайнында бөртекле һәм бөртекле - кузаклы культуралар суктыру буенча алдынгы комбайнчылар</u>**

Мичурин исемендәге КХАдан Алексей Ильич Исаев 8833 центнер ашлык суктырды.

«Мамык» КХАсыннан Веналий Николаевич Шмелев анардан 225 центнерга гына азрак суктырды.

«Заветы Ильича» КХАсы комбайнчысы Александр Николаевич Корнеевның күрсәткече 6665 центнер булды.

## ҖИРГӘ БИРСӘҢ ЧЫН КҮҢЕЛ...

Адәм баласы җылы сүзгә, ягымлы карашка мохтаҗ булган кебек, җир - ана туендыручы буларак мөнәсәбәттә торган кешеләргә, шунда күңел биреп эшләүчеләргә карата һәрчак юмарт.

- Без җирне бик хасиятләп эшкәртәбез. Җиребез күп түгел, шуңа бездә һәр гектар гына түгел, һәрбер сутый җир дә хисапта,- ди хуҗалыкның баш агрономы Вәгыйзь ага Галимов.

- Вакытында һәм тиз арада чәчү, җирне катоклау, үсемлекләр шытуга өстәмә сый бирү, дым саклауны, тигез тишелешне даими кайтырып тору, әлбәттә инде, яхшы сортлы орлыклар. Ашламалар кертүне әйтәсе дә юк инде...

Әлеге хуҗалыкта язгы чәчү вакытында да, урып - җыю чорында да булырга туры килгәне бар. Игътибар иткәнебез бар: болай да оешканлыклары, уңганлыгы белән дан тотучы югары норлатлылар мөһим кампания чорында тагын да бердәмләшәләр. Шулай булмый ни: кайчак бит аз гына битарафлык, гадәти күзгә сизелерлек булып тоелмаган салкын канлылык та ахыргы нәтиҗәләргә зур зыян салырга мөмкин. Биредәге кебек вак - вак участоклардан торган басуларда борылыш полосалары гына да күпме игътибар таләп итә бит. Әнә, 31 гектарлы басуда күлләр генә дә җидәү. Участокка тулысынча орлык күмдерү өчен әлеге кырга чәчү агрегатлары аның кипшенүенә бәйле рәвештә өч мәртәбә керергә мәҗбүрләр. 12 күлле 96 гектарлы басу да чәчү вакытында булсынмы, үсемлекләрне карау яисә урып - җыю чорындамы зур көч тә, сабырлык та сорый.

Хәер, әлеге хуҗалыкта көч, сабырлык кебек сыйфатларга ия механизаторлар аз түгел. Көздән җирне 27 - 30 сантиметр тирәнлектә әйбәт итеп әйләндереп каплап сөреп, культивацияләп, шлейфлап калдыру төп таләпкә әйләнгән. Ә инде чөгендер чәчеләсе мәйдан известьланып, ашлама кертеп үк калдырыла. Язын исә бер генә басу да үсемлекләр шыткančы һәм шыткач тырмаланмыйча калмый. Ә инде ашламалар белән эшләүгә килсәк... Аның органик һәм минераленен дә һичкайчан артыгы булмаячак, дигән фикер ныгыган хуҗалыкта. Югары Норлатта авыл кырыенда үзенә күрә бер шәһәрчекне хәтерләтүче терлекчелек объектлары тирәләрендә тиреснең өелеп ятканын һичкайчан хәтерләмиләр. Тирес сыекчасын РЖТ - 10 маркалы җайланма белән аларны һичниниди наряд - күрсәтмәсез басуга чыгаралар. Баш агроном белән махсус санап тордык, басуга көн саен уртача 100 тонна тирес чыга икән. Узган елгы уңыш астына һәр гектар 33,5 тонна тирес исәбеннән өстәмә сый алган.

Минераль ашламалар белән эшләүгә дә игътибар зур хуҗалыкта. Аның һәр граммы исәптә. Былтыр катлаулы ашламаларга, ЖКУга кытлык булса да калган төрләре җитәрлек булган. Бөртеклеләрне фосфор, азот, калийлы ашламалар белән туклaндырсалар, күпьеллык үләннәр һәм кукуруз өчен аммиак селитрасы керткәннәр. Соңгысының өч тапкыр рәт араларын эшкәрткәндә дә ашлама кулланганнар. Гомумән, һәр культура бөртек чәчкечләр белән тамырдан тукландырыла. Хәер, сиптергечләр дә кулланыла. «Кертитос» маркалы немец сиптергече сыек комплекслы ашлама сиптерү өчен бик кулай дип саныйлар хуҗалыкта.

- Җиргә чын күңел бирсәң, уңышка һәрчак юмарт була ул, - ди баш агроном, һәм, өстәп куя - халкыбыз да тырыш бит безнең.

Бәхәсләшмибез. Югары норлатлылар, кем әйтмешли, җир җимертеп эшләүчеләр. Шикәр чөгендере игү осталары Шамил Яруллин, Зәйдулла Мөхәммәтов, Солтангәрәй Мөхәммәтов - даннары районга таныган механизаторлар бит. Нәфис Бикбаев, Ислам Мусин, Зәйдулла Әхмәтсафинны әйт тагын! Соңгысы былтыр «Дон - 1500» комбайны белән бер үзе барлык басулардагы игеннәрне дә суктырып чыкты. Шундыйлар булмаса, узган корылыклы елда да бөртекләрнең һәр гектарыннан 41,3 центнер уңыш җыя алырлар идемени? Азык культуралары үстерүгә куйган хезмәтләре дә бушка китмәде. Барысына да әлеге дә баягы эшкә чын күңел бирү нәтиҗәсендә ирешелде бит.

**Р.ГИНЯЕВА.**

**<u>1996 нчы елда районның шикәр чөгендере үстерү буенча алдынгы хуҗалыклары</u>**

Хафизов исемендәге **КХА** 270 гектар җирнең һәр гектарыннан 289ар центнер татлы тамыр казып алды.

«Кондырча» күмәк хуҗалыгында ул күрсәткеч 248 центнер тәшкил итте.

Киекледә исә алардан бик азга, 2 генә центнерга калыштылар.



«Норлат - Октябрь ит комбнаты» акционерлык җәмгыяте эшләп чыгара торган продукциядә авыл хезмәтчәннәренең дә өлеше гаять саллы.

**<u>Бөртеклеләрдән иң югары уңыш алган бригадалар</u>**

Равил Шиһапович Галиев бригадасы («Рассвет» совхозы) 547 гектар мәйданның һәр гектарыннан 41,3 центнер иген суктырып алды.

Владимир Петрович Мандрейкин бригадасы (Кузнецов исемендәге **КХА**) иңләгән 510 гектар мәйданнан алынган иген гектарына 34,8 центнер тәшкил итте.

# ЕЛ ТӘҮЛЕГЕ ҖИҢНӘР СЫЗГАНУЛЫ, ИГЕЛЕГЕ БҮГЕН ШУЛ ЗУР ЭШНЕҢ

## ОЛЫ КУАНЫЧ

(Ахыры. Башы 3 нче биттә).

Инде Вәзир абый өчен эш белән өй арасы тагын да якынаеп, шактый вакыт эшкә сарыф ителә башлады. Хәзер еллар буена катлаулы хезмәттә үзен тапкан, бөтен булдыклылыгын шунда күрсәткән, олы тәҗрибә туплаган Вәзир абый үзе юллаган, эшкә өйрәткән яшьләрнең үрләр яулавын күреп сокланып та, горурланып та күзәтә. Димәк, алмаш булачак! Ә яшьрәкләр киңәшкә һаман да аңа киләләр һәм ялгышмыйлар да. Хуҗалыкның техника тармагында рационализатор, уйлап табучы буларак та олылыйлар аны. Эштән чыккан техниканы тагын ничегрәк файдаланырга мөмкин, кайсы техниканы нинди алым белән кулланганда отышлырак килеп чыга - болар һәм башка шундый мәсьәләләр Вәзир абый ярдәмендә һәрвакыт уңышлырак башкарылалар.

Хезмәт юлының бишенче дистәсе белән барганда Вәзир Хәйдәровичта һаман да уңышлы эшләү, отышлы хезмәт дәрте сүнмәгән. Язгы чәчүгә җентекләбрәк әзерләнеп, бернинди сынауларда да сынатмыйсы иде, ди ул. Холкына хас сабырлык белән шул җаваплы кампаниягә әзерлек алып бара. Бу мәсьәләдә, яшерен - батырын түгел, ул һаман да тормыш - көнкүрештә яхшы үзгәрешләргә өметләнеп, элеккечә рухны саклый. Дөрес, башкалар кебек үк игенче, терлекче - илне тукландыручының хезмәте тиешенчә бәяләнмәве, ул гына да түгел, инде ничә ай хезмәт хакын алудан мәхрүм булулары алдынгы комбайнчы - кыр батырын да борчымый калмый. Киләчәктә мул уңыш алу, үрләргә ирешү крестьянны коры энтузиазмга таяндыру ярдәмендә генә тормышка ашмаячак, дигән фикерне куәтли ул.

Шуңа карамастан, гомер үзагымына ага бирә. Быел көнчыгыш календаре буенча уңышлы ел вәгъдә итүче үгез елы алар гаиләсендә дә бер шатлыклы вакыйга - юбилей елын алып килде: Хәлиуллиннарның сикәлтәле тормыш сукмагыннан бергәләп атлауларына 35 ел тула. Бу олы гаилә бәйрәмен эшлекле нигезнең дәвамчылары - балалар, килен, кияүләре, биш оньк арасында каршы алуы ата - ана өчен олы куаныч булыр, мөгаен.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

**Шикәр чөгендере җыю комбайннарында иң алдынгы механизаторлар**

«Кондырча» КХАсыннан Әсгат Вазыхович Тәмаев КС - 6 комбайны белән 146 гектар мәйданнан 249ар центнер татлы тамыр чыгарды.

Хафизов исемендәге КХАдан Михаил Петрович Ивашкин шундый ук комбайнда 120 гектар мәйданнан 246ар центнер чөгендер алды.

Кузнецов исемендәге КХАдан Виталий Леонидович Терентьевның күрсәткече 225 центнер тәшкил итте.

# КЕРЕМНӘРНЕ САНАР ЧАК

## *Салым инспекциясе кисәтеп куя*

Район дәүләт салым инспекциясе 1996 елда төп эш урыныннан тыш та керемнәре булган физик затларның гомуми еллык кереме 12 миллион сумнан артып киткән очракта быелның 1 апреленә кадәр былтыргы фактик керемнәре турында салым инспекциясенә декларация тапшырырга тиешлекләре турында исләренә төшерә.

Декларациядә барлык чыганаклардан да алынган керем һәм алардан түләнгән салымнар турында аерым - аерым мәгълүмат күрсәтелә.

Җыелма керемне исәпләгәндә түбәндәге керем чыганаклары исәпкә алына:

- төп эш урынындагы барлык хезмәт хакы;
- башка предприятиеләрдә, хезмәт һәм уку урыннарында эшләп алган һәм эшмәкәрлек белән шөгыльләнүдән кергән керемнәр;
- ачышлар, уйлап табулар өчен алынган бүләк суммалары;
-юридик зат буларак теркәлмичә генә башкарылган эшмәкәрлектән алынган керемнәр:
- корылмаларны, фатир, бүлмәләрне, гаражларны, автомобильләрне һәм башка күчемле һәм күчемсез милекне арендага биреп торудан алынган керемнәр;
- милек сатудан (аның төренә карап 5000 яки 1000 минималь хезмәт хакы суммасыннан арткан өлешеннән) алынган керем;
- башка чит дәүләттә яки чит дәүләттән алынган керемнәр;
- акционерлык җәмгыятьләре акцияләре буенча алынган дивидендлар суммасы.

Узган календарь елда бары тик төп эш урыннарында хезмәт вазифаларын башкарудан гына керем алган физик затлар, гәрчә ел дәвамында төп эш урыннарын алмаштырган булсалар да, еллык керемнәре турында салым инспекциясенә декларация тапшырмыйлар.

Керемнәре елга 12000000 сумнан артмаган физик затларга да андый декларацияне тапшыруның кирәге юк.

Предприятиеләр, учреждение, оешмалар һәм башка эш бүлүчеләр физик затларга аларның үтенече буенча еллык керемнәре һәм түләгән керем салымнары турында белешмә бирергә бурычлылар.

Физик затлар салым органына декларация тапшырганнан соң бер ай дәвамында аңа төзәтмәләр һәм өстәмәләр тапшыра алалар.

Җыелма керем турында декларация тапшыру тәртибен бозган физик затлар гамәлдәге законнар буенча штрафка тартылырга мөмкин. Декларацияне вакытында яки бөтенләй тапшырмаган физик затларга 2дән алып 5кә кадәр минималь хезмәт хакы күләмендә административ, штраф салына, мондый закон бозу ел дәвамында кабатланса штраф күләме 5тән 10га кадәр минималь хезмәт хакы зурлыгында була.

Декларацияне тапшырмаган яки вакытында тапшырмаган гражданнарга карата тиешле керем салымның 10 проценты күләмендә финанс санкциясе дә кулланыла.

Керемен яшергән яки киметеп күрсәткән салым түләүче шул сумманы түләтү һәм шул ук күләмдә штраф салу кебек җаваплылыкка тартыла, ә бу эш кабатланганда штраф суммасы икеләтә арта.

Былтыр 165 кеше 1995 елдагы кереме турында декларация тапшырды. Аларның яртысыннан күбрәге декларацияне соңга калып, ягъни 1 апрельдән соң китерде. 90 кеше административ җаваплылыкка тартылды. Салым инспекциясенең күрсәтмәсеннән соң да җыелма керемнәре турында декларация тутырырга килмәүчеләргә карата материаллар налог полициясенә тапшырылачак.

Декларация тутыру һәм керем салымы түләүгә кагылышлы барлык сораулар белән дә район дәүләт салым инспекциясенең физик затларга салым салу бүлегенә мөрәҗәгать итәргә була. Тел.: 2 - 10 - 59.

# Юл ярырдай егетләр

Якыннан белмәгән кешенең Илфак белән Рәмисне бертуганнар дип уйлавы бик ихтимал. Һөнәрләре дә уртак, үзләре дә гел бергә шул егетләр. Армия хезмәтенә киткәнче бергәләшеп тракторчы һөнәрен үзләштерделәр, Т - 38 тракторында бергә эшләгән җирләреннән бер вакытта Армия сафларына китеп бардылар. Икесе ике җирдә хезмәт итсәләр дә бер вакытта кайтып, ял да итмичә, икесе ике Т - 38 тракторына утырдылар. Башта авылдашлары арасында түзмәсләр, шәһәргә элдертерләр әле, дип уйлаучылар да табылды. Бигрәк тә Рәмис хакында шулай фикер йөрттеләр. Өендә әле олы агасы Рамил бар, әнисе Нурания дә колхозның алдынгы сыер савучысы булып дөбердәтеп эшләп йөри, әтисе Рафик ага да инвалид булса да йорт тирәсендә эшләрлек иде. Ләкин егет читкә китәргә ашыкмады, акыллы гына, сабыр гына шул тракторында эшли бирде. Кечкенә чагында ук олыларның күренер - күренмәс чөгендер буразналарын урап рәт арасын эшкәртүләрен, тип - тигез итеп чөгендер орлыгын җиргә күмдерүләрен сокланып карап торганы бар иде. Язмыш димә: хәзер егет үзе шул хезмәттә. Алай гына да түгел, механизаторның бер дигәне булып иреште ул. Җәйләрен кырдан кайтып кермәсә, кышын тракторын ялга куя да терлекчелеккә эшкә килә. Биредә дә сынатмый ул. Ата - анасы аның турында һәрвакыт әйбәт фикер, җылы сүз генә ишетәләр. Рәмис үзе дә авыл халкының чын хөрмәтен тоя. Ә кышлар үтеп, язгы кыр эшләре төгәлләнүгә, Рәмис сабан туена хәзерләнә башлый. Сабантуй мәйданы Рәмис өчен хезмәт мәйданы төсле үк, биредә ул - үз кеше, сәләтле һәм теләкле егет. Капчык көрәшендә дә Рәмис батыр кала, колгага менгәндә дә аңа тиңнәр булмый. Герне иң күп күтәрүче дә - Рәмис. Шундый һәр яктан килгән, һәр яктан булган егет ул безнең Рәмис. Тик бер яктан гына авыл халкының эчен пошыра егет: нишләп һаман өйләнми икән? Моңа Рәмис үзе елмая гына: егет кеше картаймый ла ул, шулай бит, Илфак? - ди. Илфакка атап дәшүе тикмәгә түгел, анысы да гаиләсен корып өлгермәгән әле. Ул да булдыклы механизатор, өстәвенә бик игелекле эш тә башкара: бик хөрмәтләп ялгыз әбисен тәрбияли, шуңа да авыл халкы аңа икеләтә хөрмәт белән карый. Илфак та кышкы чорда тракторын куеп терлекчелеккә эшкә килә. Егетләрнең хезмәтеннән ферма җитәкчеләре бик канәгатьләр. - Алар караган маллар өчен җаныбыз тыныч, - диләр алар. - Үзвакытында ашатылган, аслары чиста, үзләре көр үсәләр.

Егетләр чыннан да терлекчелекне вакытлыча эш итеп карамыйлар. Шулай да механизатор егетләр язны үзенчә бер ашкынулы сагыну белән көтәләр. Кояш җылырак карый башлау белән алар чөгендер агрегатларын кыр эшләренә әзерләү мәшәкатенә керешәчәкләр. Быелгы язгы чәчүнең тагын да җаваплырак булачагын яхшы аңлыйлар алар: хуҗалыгыбыз ереләнде, басулар кинәйде, бурычлар да үсте. Район күләмендә бөртеклеләр уңышын гектарга 40 центнерга җиткерү максаты куелганда Илфак Кәлимуллин, Рәмис Нәмаев кебек яшь көч, тырышлык юл ярып барырга тиешләр бит.

**И.ШӘЙХИЕВ.**
**Зирекле авылы.**

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Кадерле әниебез **Сания Хабибулла кызы Яруллинага** быел 60 яшь тула. Әтиебез белән бергә торуларына 40 ел була. Аларның тигез тормыш белән яшәүләре, тату гомер кичерүләре безнең өчен зур бәхет. Аларга сәламәтлек, бәхетле картлык телибез.



Безнең күңел һәрчак сезгә
Тели бит изге теләк.
Җир йөзендә сездән башка
Берни юк кадерлерәк.

**Изге теләкләр белән барлык балалары, киленнәре, кияүләре һәм оныклары.**



*Норлатта яшәүче безнең өчен иң якын булган кешебез **Сәрвәрия Шәкүр кызы Ягудинаны** 70 яшьлек юбилее белән чын күңелдән тәбрик итәбез.*

*Юбилееӊ котлы булсын,*
*Гомерең үтсен шатлыкта.*
*Кайгы күрмә, чирне белмә,*
*Һич бирешмә картлыкка.*

***Иң изге теләкләр белән Шакир һәм Фирдәвес Хәсәнҗановлар гаиләсе.***

## Белдерүләр ● Белдерүләр

**Сатабыз**



**Гараж чанасы.** Адрес: Промышленная ур., 2 - 1.

***

**Октябрьская ур., 82 адресы буенча 2 бүлмәле фатир. Декабристлар ур., 35 адресы буенча теләсә кайчан мөрәҗәгать итәргә.**

***

**Богдашкинода йорт.** 2 - 19 - 00 телефоны буенча Тихоновага шалтыратырга.

***

**«НАППА» АҖ ял көннәрне иртәнге сәгать 7 дән базарда машинадан ирләр, хатын - кызлар һәм балалар өчен натураль күннән тегелгән аяк киемнәре сата.**

***

**Ике камералы «Стинол» суыткычлары сатыла.** (Белешмә № 445). Китап кибетенә (2 нче кат) яки 2 - 21 - 02 телефоны белән мөрәҗәгать итәргә.

***

**1991 елгы ВАЗ - 21043.** Тел.: 5 - 20 -23.

***

**Фатир кирәк**

**Торырга фатир эзлим.** Тел.: 5 - 28 - 35 (көндезге 1 дән кичке 9га кадәр).

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2047 данә. Заказ N 5144.